РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28.12.2022 ел № 156

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына (район Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 140 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 4 нче абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 12688 сум тәшкил итә»;

1.2. III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында 1 нче кушымтада бәян итәргә «6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә».

1.3. 2 нче кушымтаны «Муниципаль район башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең муниципаль районда даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләме», кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.4. 7 нче кушымтаның 1 нче пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш, айлык акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Чирмешән муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов